Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Югары Ырга
авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 2**

Югары Ырга авылы 2020 елның 4 нче феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге Советының 20 14 елның 6 нчы октябрендәге “Җир салымы турында” 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, 2019 елның 29 сентябрендәге “Россия Федерацисе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында” 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге Советының “Җир салымы турында” карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге Советының 2014 елның 5 нче ноябрендәге 12/1 номерлы, 2015 елның 22 нче маендагы 9/1 номерлы, 2019 елның 14 нче июнендәге 8 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән гайре) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән гайре) җир кишәрлекләренә карата -0,3%”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга җирлегенең Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авылы, М.Җәлил урамы, 18 нче йорт; Яңа Ырга авылы, Мәктәп урамы, 48 нче йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Югары Ырга авыл җирлеге
Башлыгы Баһаутдинов Ринат Нуретдин улы

СОВЕТ ШЕТНЕВО-ТУЛУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1634001687 ЮГАРЫ ЫРГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН РЫБНО-СЛОБОДСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ Р 06-155/02